3 сыйныфта татар теле дәресе

# “Сыйфат” темасы буенча белемнәрне гомумиләштерү

Укытучы: Нургалиева Л.Ф.

ң

~~н~~ ,



,,,



чаңгы



**Предметның билгесен белдереп, нинди? кайсы? сорауларына җавап булган сүзләр сыйфат дип атала.**



***Сыйфатлар җөмләдә исемгә бәйләнеп киләләр.***

***Исем предметны , ә сыйфат предметның билгесен белдерә, шуңа күрә җөмләдә сыйфатлар исемгә бәйләнеп килә.***

Сыйфатлар җөмләдә хәбәр дә булып килә.

Кош түгел , оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны

Алгы тәпие кыска.
Чабарга ул бик оста.
Соры тунын сала да
Ак ту





Җәй шакылдый
бу чүкеч,
Кыш шакылдый
бу чүкеч,
Ничек чыдый
бу чүкеч?

Нечкә билле,
Кө ы.





**Сыйфатлар предметларның төрле билгеләрен белдерәләр:**

***төсне:*** *зәңгәр, ак, яшел;*

***тәмне:*** *ачы, төче, татлы, баллы;*

***форманы:*** *озын, түгәрәк, кәкре, кыска;*

***холыкны:*** *көләч, усал, юаш, сизгер, куркак;*

***вакытны:*** *кышкы, быелгы, иртәнге;*

***табигать күренешләренең билгеләрен:*** *буранлы, яңгырлы, җилле, аяз.*

**Сыйфатлар сөйләмне матурлыйлар. Алар предметларны, күренешләрне төрле яктан сурәтлиләр.**







**Тест**

**1.Сыйфат нәрсәне белдерә?**

а) предметның эшен, хәрәкәтен;
б) предметны;
в) предметның билгесен.

**2. Сыйфат нинди сорауларга җавап бирә?**

а) кем? нәрсә?
б) нинди? кайсы?
в) нишли? нишләде? нишләгән? нишләячәк?нишләр?

**3. Кайсы төркемдә сыйфатлар гына бирелгән?**

а) унган, сары, озын, иркен, кайнар;
б) кояш, ямьле, болытлы, җилле;
в) исле, баллы, мин, сабыр.

**4. Сыйфат җөмләдә:**

а) исемгә бәйләнеп килә;
б) фигыльгә бәйләнеп килә.



**5.Кайсы җөмләдә хәбәр сыйфат белән белдерелгән?**

а) Урманда һава чиста.
б) Куян ак кар өстеннән чаба.
в) Купшы карабүрекләр җим чүпли.

***Билге:***
***5 дөрес җавапка-  “5”***
***4 дөрес җавапка-  “4”***
***3 дөрес җавапка-  “3”***



